СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

11.08.2020 г.Зеленодольск № 505

2020 елның беренче яртыеллыгында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан акчалар тоту турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закона, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына, Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмәгә таянып, 2020 елның беренче яртыеллыгында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондының акчаларын тоту турында «Зеленодольск муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе О.П. Дёгтеваның мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар итте**:

1. 2020 елның беренче яртыеллыгында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту турында мәгълүматны исәпкә алырга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы урынбасары** **Э. Р. Кадникова**

***01.07.2020 ел торышы буенча Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондының акчаларын тоту турындагы белешмәләр***

| ***№ т/б*** | ***Түләү билгеләнеше*** | ***Сумма (сум)*** |
|---|---|---|
| | | 309 853,52 |
| 1 | Дәвалауга матди ярдәм күрсәтү, матди ярдәмнең башка төрләре | 25 000,00 |
| 2 | Мактаулы гражданнарның вафатына бәйле рәвештә матди ярдәм күрсәтү | 27 050,00 |
| 3 | 2020 елның 14-19 гыйнварында грек - рим көрәше буенча Россия чемпионатында мәктәп тәрбияләнүчеләре катнашу сәбәпле, тренер Данилов А. Н. Новосибирск шәһәрендәге командировка чыгымнарын түләү өчен. | 15 600,00 |
| 4 | «Кунакчыллык осталыгы» Бөтенроссия һөнәри конкурсында, Ялта шәһәрендә, 2020 елның 11 мартыннан 13 мартына кадәр «Зеленый Дол» ИЦ» ЗМР АУ ның туризм буенча җитәкче урынбасары катнашуы өчен транспорт чыгымнарын кайтаруга | 102 439,00 |
| **5** | 2020 елда «Берләшкән шәһәрләр һәм җирле хакимиятләр» Бөтендөнья оешмасының Евразия төбәк бүлеге» халыкара ассоциациясенә әгъза взносын түләү өчен | 50 000,00 |
| **6** | Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районы Хәрби комиссариаты хезмәткәрләренә матди ярдәм түләү | 27 600,00 |
| 7 | Ирекле халык дружиналары (ДНД) дружинникларына матди ярдәм түләү | 115 000,00 |
| 8 | Эчке эшләр министрлыгы (МВД) бүлеге хезмәткәрләренә матди ярдәм күрсәтү | 12 860,00 |
| 9 | Зеленодольск муниципаль районында коронавирус пандемиясенә бәйле рәвештә, ялгыз һәм ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнарга үз вакытында ярдәм тәэмин итүче волонтерлар өчен яклау чараларын сатып алу | 60 000,00 |
| 10 | Зеленодольск муниципаль районы территориясендә коронавирус йогышы таралуга юл куймау максатларында, «Сәламәтлек битлеге» социаль акциясен үткәрү өчен 2000 данә күләмендә медицина битлекләре сатып алу | 322 060,98 |
| 11 | Зеленодольск муниципаль районы территориясендә үз-үзеңне изоляцияләү режимының үтәлешен контрольдә тоту чараларын тормышка ашыруда катнашучы Россия Эчке эшләр министрлыгының Зеленодольскрайоны буенча бүлеге хезмәткәрләренең туклануын оештыру хезмәте өчен түләү | 23 000,00 |
| 12 | Демеркуризация (терекөмешле пычратуларны бетерү һәм терекөмешле калдыкларны утильләштерү буенча чаралар) үткәрү өчен. | 79 000,00 |
| 13 | "Хронография-2019"тамашачы фильмын һәм "Бу безнең синең белән биография..." фильмын әзерләүгә. | 40 000,00 |
| 14 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау чаралары турында «2020 елның 19 мартындагы 208 номерлы карарын тормышка ашыру чаралары хакында» 2020 елның 31 мартындагы 240 номерлы карары таләпләрен үтәү кысаларында, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә үзизоляция режимын үтәүне тикшереп тору чараларын гамәлгә ашыруда катнашучы махсуслаштырылган хезмәтләрне тәэмин итү максатларында,1000 данә күләмендә саклагыч битлекләр тегү буенча хезмәтләр өчен | 229 888,00 |
| 15 | 22.05.2020 елда «Зеленодольск РҮХ» ДАССОда янгында һәлак булган һәм зыян күргән кешеләрнең туганнарына матди ярдәм күрсәтү өчен . | 396 070,00 |
| 16 | Россия Федерациясе Конституциясенә төзәтмәләр буенча тавыш бирү процедурасын оештыру өчен кирәкле чатырларны һәм биотуалетларны арендалау буенча хезмәт | 37 800,00 |
| 17 | Шәһәр һәм районның күп балалы гаиләләренә 2020 елның икенче яртыеллыгына «Яшел Үзән» газетасына язылу квитанцияләре өчен | 45 200,00 |
| 18 | Зеленодольск муниципаль районында иреклеләр эшчәнлеген үстерү кысаларында волонтерлар өчен экипировка алу. | |

| | | |
|---|---|---|
| 19 | Зеленодольск муниципаль районының чакырылыш комиссиясе эшен тәэмин итү өчен коронавирус йогышын профилактикалау һәм аңа каршы тору чараларын сатып алу | 83 800,00 |
| 20 | 2020 елның 24 июненнән 2 июлена кадәр 3 стационар сайлау участокларының (палаткаларның) сакланышын тәэмин итү буенча «Армата-1» ХСШ хезмәтләренә түләү өчен . | 38 400,00 |
| **БАРЛЫГЫ** | | **2 040 621,50** |

ФБП җитәкчесе О.П. Дёгтева